ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЗУР СӘРДЕК АВЫД ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАРЫ

07 апрель 2023 ел №24

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Зур Сәрдек авыл җирлеге» («Зур Сәрдек авыл җирлеге») муниципаль берәмлеге территориясендә эштән чыгарылган терекөмешле лампалар туплау урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашу урыны турында мәгълүмат бирү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Тиешенчә булмаган җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре ( Зур Сәрдек авыл җирлеге) территориясендә эштән чыгарылган терекөмешле лампалар туплау урынын (урыннарын) билгеләргә: Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Зур Сәрдек авылы, Централь ур, 141 йорт.

2. Күп фатирлы йортларның милекчеләре, яллаучылары, кулланучылары булган терекөмешле лампалар кулланучыларның эштән чыгарылган терекөмешле лампаларын туплау урыннары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган Тиешенчә булмаган җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләренең 4 пункты нигезендә билгеләнә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән эштән чыгарылган терекөмешле лампаларны туплау урыннары, әлеге күп фатирлы йортларда туплау урыннарын оештыру өчен биналар булмау сәбәпле, эштән чыгарылган терекөмешле лампаларны туплау урыннарын оештыру мөмкин булмаган очракта, шул исәптән күп фатирлы йортларның милекчеләре, яллаучылары, кулланучылары булган терекөмешле лампаларны кулланучылар өчен дә билгеләнгән дип билгеләргә.

4. Кулланучыларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре (Зур Сәрдек авыл җирлеге) территориясендә эштән чыгарылган терекөмешле лампалар туплау урынының (урыннарының) урнашкан җире турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында,Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре (Зур Сәрдек авыл җирлеге) җирле үзидарә органнары биналарында мәгълүмати стендларда (стойкаларда) урнаштыру юлы белән хәбәр итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында, район массакүләм мәгълүмат чарасында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре ( Зур Сәрдек авыл җирлеге) башкарма комитеты җитәкчесенә калдырырга.

Зур Сәрдек авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе Ф.М.Фаттахов